КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 30 декабрь г.Казань № 1140

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларда предприятиеләрдә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган инвалидларның эш урыннарын саклауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларда предприятиеләрдә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган инвалидларның эш урыннарын саклауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 18 июль, 524 нче, 2015 ел, 17 декабрь, 959 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«2015 – 2020 елларда инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклау белән бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән 2015 – 2020 елларда инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклау белән бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.»;

әлеге карар белән расланган 2015 – 2020 елларда инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклау белән бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин